РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕМЕШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Школьная ул., д. 1, с. Большая Меша, 422088
тел.: (84360) 55-1-45,
E-mail: Bms.Tul@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ МИШӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Мәктәп ур., 1 нче йорт, Олы Мишә авылы, 422088
тел.: (84360) 55-1-45,
E-mail: Bms.Tul@tatar.ru

ОКПО 94318205 ОГРН 1061675010980 ИНН/КПП 1619004468/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 21** **«21» октябрь 2021 ел.**

Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлеге башкарма комитетының 01.03.2016 елның 4 номерлы «Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлеге территориясендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү тәртибе турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы Федераль закон нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлеге башкарма комитетының 01.03.2016 елның 4 номерлы «Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлеге территориясендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү тәртибе турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлеге чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү тәртибе турында Нигезләмәгә:

1) 2 бүлектә:

А) 2.3 пунктта «дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар китерүгә, эшләр башкаруга һәм хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру» сүзләрен «дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү» сүзләренә алмаштырырга.

2. Олы Мишә авыл җирлеге бюджетыннан беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү чыгымнарын финанслау Тәртибенә:

А) 1 пунктта «дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар китерүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру» сүзләрен

«дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу» сүзләренә алмаштырырга;

Б) 4 пунктта «шартнамәләр төзи» сүзләрен «дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашыра» сүзләренә алмаштырырга, «муниципаль ихтыяҗлар өчен заказлар урнаштыру» сүзләрен «дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу» сүзләренә алмаштырырга.

3. Муниципаль оешмаларда янгын куркынычсызлыгы чаралары турында инструкцияләрнең (нигезләмәләрнең) төрләренә, эчтәлегенә һәм бәян ителешенә Төп таләпләр:

1) 2 бүлектә:

А) 2.1 пунктта «Россия Федерациясендә янгын куркынычсызлыгы Кагыйдәләрендә китерелгән» сүзләрен «гамәлдәге янгынга каршы нормалар белән»сүзләренә алмаштырырга.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Ф.Б.Замалетдинов